

Гадәт буенча, һәр елны Зубово-Поляна районы татар авылларында - Тат.- Лундан, Кочетовка, Горенка авылларында “Кыр кырбаны” vткәрәләр.
25 май конне Татар Лундан авылы халкы кырда дога кылып, корбан итеннән бергәләп шулпа пешереп, авыл яше-карты йолада катнашканнар.
“Бу ата-бабаларыбыздан сакланып калган бәйрәм; кайсы авылда vткәрсәләр дә, барлык авыл халкы очен уртак. Корбан бәйрәме - моселман мәдәниятендә ин моһим бәйрәмнәрнен берсе.



Анын даими датасы юк: ул Ураза бәйрәменнән сон житмеш кон узгач билгеләп vтелә”, - дип язалар авыл сайтында.
Ә гомерен мәгариф эшенә багышлаган Светлана Филипповна Ромайкина “Кыр корбаны” турында болай дип сойләде: “Кыр корбаны” бәйрәме дога кылу белән башлана, ә аннары Аллаһы Тәгаләдән уныш мул булып vсvне, доньяларда тынычлык булуны, тәбигатьнен рәхимле булуын сорап, корбан бугазлана. Чарада яше-карты катнашты, шул исәптән Горенка мәктәбе укучылары да. Бу бик яхшы һәм моһим, чонки буыннар элемтәсе югалмый, традицияләрне vзләштерәләр һәм балалар vз балаларына тапшырачаклар.”



Белгәнебезчә, шушы олы милли бәйрәмне бергә-бергә әзерлиләр, хәтта Мәскәvдә, Питерда яшәvче якташлары да сәдака жибәреп бәйрәмдә читтән торып катнаша. “Кыр корбанын” хормәт итеп, башка милләт кешеләре дә чарада катнаша. Казаннарда ит, салма пешереп барчасы сыйлана. Кырда vткәргән бәйрәмгә килә алмаган картларга аш-суны ойләренә илтеп бирәләр.
(Фотолар Горенка мәктәбе
сайтыннан алынды)